**УКАЗ**
РАИСА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
РӘИСЕ
**УКАЗЫ**

# Татарстан Республикасының аерым территорияләрендә хайваннар котыру авырулы булганга, аларның имин булмавы сәбәпле кертелгән чикләү чараларын (карантинны) бетерү турында

Котыру чиренә бирешүчән соңгы авыру хайванның үләксәсе юкка чыгарылган көннән 60 календарь көн узуы, эпизоотиягә каршы һәм профилактик чаралар уздырылу белән бәйле рәвештә, «Ветеринария турында» 1993 елның 14 маендагы 4979-I номерлы Россия Федерациясе Законының $3^1$ статьясы нигезендә **карар бирәм:**

1. Татарстан Республикасының түбәндәге аерым территорияләрендә, аларның имин булмавы сәбәпле кертелгән чикләү чараларын (карантинны) бетерергә:

а) эпизоотия чыганакларында:

«Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Аксар авыл җирлеге Перцовка авылындагы Дача урамы 39 нчы йортның шәхси ярдәмче хуҗалыгы территориясе;

«Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Югары Шепкә авыл җирлеге Югары Шепкә авылындагы Үзәк урамы 76 нчы йортның шәхси ярдәмче хуҗалыгы территориясе;

«Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Чукмарлы авыл җирлегендә урнашкан, төньяк киңлекнең 55,262181° һәм көнчыгыш озынлыкның 52,418653° географик координатларыннан 1 км радиустагы территория;

б) имин булмаган пунктларда:

«Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Аксар авыл җирлегендә урнашкан, әлеге пунктның «а» пунктчасы икенче абзацында күрсәтелгән эпизоотия чыганагы чикләреннән 1 км радиустагы территория;

«Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Югары Шепкә һәм Аксар авыл җирлекләрендә урнашкан, әлеге пунктның «а» пунктчасы өченче абзацында күрсәтелгән эпизоотия чыганагы чикләреннән 2 км радиустагы территория;

«Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Чукмарлы һәм Илексаз авыл җирлекләрендә урнашкан, әлеге

пунктның «а» пунктчасы дүртенче абзацында күрсәтелгән эпизоотия чыганагы чикләреннән 1 км радиустагы территория.

2. Татарстан Республикасы Рәисенең «Татарстан Республикасының аерым территорияләрендә хайваннар котыру авырулы булганга, аларның имин булмавы сәбәпле чикләү чаралары (карантин) кертү турында» 2025 елның 2 сентябрендәге 699 номерлы Указы үз көчен югалткан дип танырга.

3. Әлеге Указ аңа кул куелган көннән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы Рәисе** **Р.Н. Миңнеханов**

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ РӘИСЕ АДМИНИСТРАЦИЯСЕ • АДМИНИСТРАЦИЯ РАИСА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ГОМУМИ БҮЛЕК
ОБЩИЙ ОТДЕЛ

Казан, Кремль
2025 ел, 07 ноябрь
№ 919